**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Совет Кошкинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Кошки авыл җирлеге Советы**

Адрес: 422892, РТ, Алькеевский район с.Кошки, ул. М.Джалиля, 18
факс: 8 (84346) 73-2-50

Адресы: 422892, РТ, Әлки районы, Кошки авылы, М.Джалиля ур, 18
тел: 8 (84346)73-2-50

**Карар** **Кошки авылы** **Карар**

2025 елның 17 июнендәге № 126А

## Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Кошки авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

“Россия Федерацисе гражданнары сайлау хакукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 105 статьясындагы 1 өлеше белән 21-ТРЗ, “Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Кошки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Кошки авыл җирлеге Советы **кабул итте:**

**1.**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бишенче чакырылыш Кошки авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләрергә.

**2.** Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының хокуки мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгару (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының “Интернет” телекоммуникацион-мәгълүмат челтәрендәге рәсми сайтында (https://alkeevskiy.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Кошки авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Адреслары:

Кошки авылы, М. Җәлил ур., 18 йорт (административ бина);

Татар Төгәлбәе авылы, Шәвәлиев ур., 8Б йорт (мәдәният йорты бинасы).

**3.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Кошки авыл җирлеге
Советы рәисе

И.Н. Сираев